**Пәйгамбәребез (с.г.в) әйтте:**

# Кальбебез төзек булсын

Бәдер сугышында җиңеп кайткач, Пәйгамбәребез (с.г.в.) алда тагын да зуррак җиһад барлыгын әйтә.

Сәхабәләр гаҗәпләнә:

«Инде шундый зур сугыштан да зуррак җиһад була аламы, йә, Аллаһының рәсүле, без бит әле җиңеп кайттык кына. Ул нинди җиһад?» - дигәч,

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә:

**«Нәфесебез белән сугыш».**

Бу хәдискә уйларымда кабат-кабат әйләнеп кайтам.

Кардәшләрем, менә бу дөньяда безгә нинди генә һөҗүм юк.

Ул - шайтан коткысы,
тәкәбберлек,
мин-минлек.
Сине кимсетәләр,
сиңа төкерәләр,
синең динеңне,
милләтеңне мыскыллыйлар
һәм бу һөҗүмнең очы-кырые күренми.

Сорау туа.

Ничек боларга каршы торырга?

Ничек кеше булып калырга?

Әле бер көн бер кардәшем мәчеттә бер хәдисне китерә.

**«Акыл - кальбнең колагы»,** - ди.

Димәк, кальб ни әйтә - акыл шуңа буйсына.

Бу хакта Пәйгамбәребез (с.г.в.) дә әйткән:

«Кешедә бер әгъза бар. **Шул төзек булса, кеше дә төзек. Шул әгъза бозык булса, кеше дә бозык».**

Кешенең һәр гамәле кальбкә бәйләнгән.

Һәр әгъзабыз төзек булсын өчен кальбебезне тәрбияләргә кирәк.

Әгәр тәрбия кылабыз икән - ул исән.

Ә әһәмият бирмибез икән - ул чирләргә дә мөмкин.

**Ә ничек тәрбияләп була соң кальбне?**

Изгелекләр белән.

Әгәр кешенең йөзенә игътибар итсәгез, кайсыбер кешенең йөзеннән нур бөркелеп торуын күрерсез. Менә шушы нур бөркелеп торган кешенең гамәленә карагыз. Бу кеше олы йөрәкле була, изгелекләр эшли. Гөнаһка бармый.

Ә караңгы йөзле кеше булса, аның гамәлләре дә шулай. Ул тар күңелле, үзе өчен генә яши. Ул бернигә риза түгел, изгелекнең ни икәнен дә белми.

Кайберәүләребез әйтер:

**«Бар намаз укучылар, ураза тотучылар. Алар арасында да тар күңелләләр бар».**

Әйе, бар.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә Пәйгамбәребез (с.г.в.)гә әйтә:

«Без сине күркәм холык белән китердек. **Әгәр каты күңелле булсаң, синең яннан качып бетәрләр иде».**

Димәк, динебезнең нигезендә күркәм холык тора. Карагыз әле, Аллаһы безгә нигъмәтләрне ничек дөрес итеп биргән.

**Кояшны алыйк.**

Ул яктысын, җылысын һәммә җиргә дә тигез итеп өләшә.

**Карыйк җилне**.

Һәр җиргә дә тигез итеп исә.

Безгә Аллаһы күңел бирде. Күңел җылыбызны һәр җиргә дә тигез итеп өләшә беләбезме?

**Безгә Аллаһы изге сүзләр сөйләү өчен телне бирде.**

Без аны ничек кулланабыз?

Тирә-якка ачу чәчәбез түгелме?

Башка кешеләргә түгел, ә үзебезнең гаиләбездә дә бер-беребезгә игътибар җитми.

Хәтта туган белән туган пычакка килә.

**Динебез Исламча яшәмибез.**

**Милләтебезне әкрен-әкрен бетерәбез.**

Инде картаеп беткән әби-бабайларыбыз оныгы белән урысча сөйләшкән була.

Кеше нинди телдә аралаша - шулардан.

Татар телен белмәгән оныкларыбыз инде татар түгел.

**Урысча сөйләшеп кенә, оныкларыбызны министр итә алмабыз.**

**Илгә шул кадәр министрлар кирәк тә түгел.**

Ә менә балаларыбызны милләт, кеше буларак югалтырбыз.

Башында зиһене булса, ул барыбер кеше була. Ә акылы, зиһене булмаса, урысча сөйләштереп кенә, әллә кем итә алмабыз.

Без авылларда үстек, урысчаны да камил белмәдек. Әмма югалып калмадык, укыдык та, җитәкче урыннарда да эшләдек, тормышта үз урыныбызны таптык.

Шуңа күрә тормышта иң мөһиме - кеше булып калу.

Кальбебезне дөресләп тору.

Милләтебезнең иң матур сыйфатларын үзебездә туплап, аларны яшь буынга мирас итеп калдыру.

**Рәис хәзрәт ӘХМӘТОВ.**

Хиҗри буенча 1434 ел

## Намаз вакытлары | Июль ае тәкъвиме | Время намазов

Милади буенча 2013 ел

| Көннәр саны | | Хиҗри буенча | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Зәвәл | Өйлә | Икенде | Ахшам | Көн озынлыгы | Ястү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | дүшәмбе | 24 Шәгъбән | 2:45 | 4:15 | 12:44 | 13:05 | 18:24 | 21:13 | *6:58* | 22:43 |
| 2 | сишәмбе | 25 | 2:46 | 4:16 | 12:44 | 13:05 | 18:24 | 21:13 | *16:57* | 22:43 |
| 3 | чәршәмбе | 26 | 2:47 | 4:17 | 12:44 | 13:05 | 18:24 | 21:12 | *16:55* | 22:42 |
| 4 | пәнҗешәмбе | 27 | 2:48 | 4:18 | 12:44 | 13:05 | 18:23 | 21:12 | *16:54* | 22:42 |
| 5 | җомга | 28 | 2:49 | 4:19 | 12:44 | 13:05 | 18:23 | 21:11 | *16:52* | 22:41 |
| 6 | шимбә | 29 | 2:50 | 4:20 | 12:45 | 13:05 | 18:23 | 21:11 | *16:51* | 22:41 |
| 7 | якшәмбе | 30 | 2:50 | 4:20 | 12:45 | 13:05 | 18:23 | 21:10 | *16:50* | 22:40 |
| 8 | дүшәмбе | 31 | 2:51 | 4:21 | 12:45 | 13:05 | 18:22 | 21:09 | *16:48* | 22:39 |
| 9 | сишәмбе | Рамазан 1 | 2:52 | 4:22 | 12:45 | 13:05 | 18:22 | 21:09 | *16:47* | 22:39 |
| 10 | чәршәмбе | 2 | 2:54 | 4:24 | 12:45 | 13:05 | 18:22 | 21:08 | *16:44* | 22:38 |
| 11 | пәнҗешәмбе | 3 | 2:55 | 4:25 | 12:45 | 13:05 | 18:21 | 21:07 | *16:42* | 22:37 |
| 12 | җомга | 4 | 2:56 | 4:26 | 12:45 | 13:05 | 18:21 | 21:06 | *16:40* | 22:36 |
| 13 | шимбә | 5 | 2:57 | 4:27 | 12:46 | 13:05 | 18:20 | 21:05 | *16:39* | 22:35 |
| 14 | якшәмбе | 6 | 2:58 | 4:28 | 12:46 | 13:05 | 18:20 | 21:04 | *16:36* | 22:34 |
| 15 | дүшәмбе | 7 | 2:59 | 4:29 | 12:46 | 13:05 | 18:19 | 21:03 | *16:34* | 22:33 |
| 16 | сишәмбе | 8 | 3:01 | 4:31 | 12:46 | 13:05 | 18:19 | 21:02 | *16:31* | 22:32 |
| 17 | чәршәмбе | 9 | 3:02 | 4:32 | 12:46 | 13:05 | 18:18 | 21:01 | *16:29* | 22:31 |
| 18 | пәнҗешәмбе | 10 | 3:03 | 4:33 | 12:46 | 13:05 | 18:18 | 21:00 | *16:27* | 22:30 |
| 19 | җомга | 11 | 3:05 | 4:35 | 12:46 | 13:05 | 18:17 | 20:58 | *16:23* | 22:28 |
| 20 | шимбә | 12 | 3:06 | 4:36 | 12:46 | 13:05 | 18:16 | 20:57 | *16:21* | 22:27 |
| 21 | якшәмбе | 13 | 3:08 | 4:38 | 12:46 | 13:05 | 18:16 | 20:56 | *16:18* | 22:26 |
| 22 | дүшәмбе | 14 | 3:09 | 4:39 | 12:46 | 13:05 | 18:15 | 20:54 | *16:15* | 22:24 |
| 23 | сишәмбе | 15 | 3:10 | 4:40 | 12:46 | 13:05 | 18:14 | 20:53 | *16:13* | 22:23 |
| 24 | чәршәмбе | 16 | 3:12 | 4:42 | 12:46 | 13:05 | 18:13 | 20:51 | *16:09* | 22:21 |
| 25 | пәнҗешәмбе | 17 | 3:13 | 4:43 | 12:46 | 13:05 | 18:12 | 20:50 | *16:07* | 22:20 |
| 26 | җомга | 18 | 3:15 | 4:45 | 12:46 | 13:05 | 18:12 | 20:48 | *16:03* | 22:18 |
| 27 | шимбә | 19 | 3:17 | 4:47 | 12:46 | 13:05 | 18:11 | 20:47 | *16:00* | 22:17 |
| 28 | якшәмбе | 20 | 3:18 | 4:48 | 12:46 | 13:05 | 18:10 | 20:45 | *15:57* | 22:15 |
| 29 | дүшәмбе | 21 | 3:20 | 4:50 | 12:46 | 13:05 | 18:09 | 20:44 | *15:54* | 22:14 |
| 30 | сишәмбе | 22 | 3:21 | 4:51 | 12:46 | 13:05 | 18:08 | 20:42 | *15:51* | 22:12 |
| 31 | чәршәмбе | 23 | 3:23 | 4:53 | 12:46 | 13:05 | 18:07 | 20:40 | *15:47* | 22:10 |
| | Дни | Хиджри | Фаджр | Восход | Зенит | Зухр | Аср | Магриб | Долгота дня | Иша |

**Мәгънәле һәм үзебезчә**

## Балаларыгызга түбәндәге исемнәрне кушыгыз

**Вагыйз** - әхлак өйрәтүче

**Вазыйх** - ачык, анык, ачык итеп аңлатучы

**Ваис** - бүре баласы

**Вакыйф** - белемле, акыллы

**Васыйл** - теләккә ирешүче

**Вафа** - тугрылык

**Вафир** - бай, киң күңелле

**Вахит** - берданбер, беренче

**Ваһап** - бүләк итүче

**Вергаз** - көч, куәт

**Вилдан** - оҗмах хезмәтчесе

**Вәли** - хуҗа

**Вәлиулла** - Аллаһының дусты

**Вәсил** - аерылмас дус, көтә белүче

**Вәсим** - бик чибәр

**“Шигырьдә хикмәт бар”**

## Аңладым...

Аңладым ул Аллаһының барлыгын вә берлеген,
Дөньяны юктан яраткан, безне бар иткәнлеген,
Тиңдәше юк, охшашы юк, рәхмәте чиксез Аның,
Ул ирекле, ул белемле, кодрәте тиңсез Аның.
Айны, көнне, таңны, төнне - ул яралткан барчасын,
Җәйне, кышны, язны, көзне - ул яралткан һәммәсен.
Дөньяда булган бөтен әйбер - Аңадыр һәммәсе,
Безне дә юктан яралткан, без дә - Аның бәндәсе.
Чын күңел берлән, иман белән ышанам Аллаһыга,
Бар теләкләремне теләп, тәүфыйк сорап, табынам Аңа.

**Мөхәммәд-Садыйк Иманколый.**
**1924 ел.**

## Ни тәм бар кардәшең итен ашаудан?

Зәһәр тулган эчең, син бер елансың,
Еланнан да явыз, эттән ямансың!
Елан бер чакса, зәһәре калмый эчтә,
Синең зәһәрең гомерлек, бетми һич тә.

Бераз этләр дә инсаф итә кайчан.
Син булдың явыз тешләүче җан.
Бәлки, эттән дә тешләтмәк - фазыйләт,
Еланнан да чагылмаклык - ганимәт.

Елан чакмас еланны һич заманда,
Дуслык вә сердәшлек бар аларда.

Эшең, кәсбең, һөнәрең, ирлегең - шул,
Тормышың шул фетнәчелектә мәшгуль.
Ни ләззәт бар шул эш белән яшәүдән?
Ни тәм бар кардәшең итен ашаудан?

Әгәр ач булса карның, балчык аша,
Аша, дуңгыз кебек, кит, бар, чык анда.

**Вакыйф ҖӘЛАЛ.**